| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |
| ***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*** | ***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*** |
| ***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | ***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

---

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

27 июнь 2022ел № 3-20

Буа муниципаль районы Буа шәһәренең
Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Буа муниципаль районы Башлыгы урынбасарының Буа шәһәр Советының 2021 елның 18 мартындагы 2-8 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгы урынбасары мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссия бәяләмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, ТР Буа шәһәр Советы карар итте:

1. Әйләнгеч ур., 7(кадастр номеры 16:14:990110:193) адресы буенча урнашкан территорияне үзгәртү өлешендә, Шәхси торак йортлар төзү зонасы – Ж1 зонасыннан Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге - Д1 зонасына үзгәртеп, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә (кушымта).
2. Гагарин (кадастр номеры 16:14:990107:1549) урамы буенча урнашкан территорияне үзгәртү өлешендә, Шәхси торак йортлар төзү зонасы – Ж1 зонасыннан 5 каттан артмаган азкатлы торак йортлар төзү зонасы– Ж2 зонасына үзгәртеп, Буа муниципаль районы Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә (кушымта).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов